ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«24 »март 2021 ел № 61-р

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу-2021» массакүләм чаңгы ярышлары үткәрү турында

Чаңгы узышларын популярлаштыру һәм үстерү, халык белән сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм эшне камилләштерү, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә этәргеч бирә торган шартлар тудыру, иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында ярышларда катнашучылар арасында спорт осталыгын арттыру максатларында:

1.«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу-2021» массакүләм чаңгы ярышларын үткәрү датасы дип 2021 елның 26 мартын, чараны үткәрү урыны дип - Әгерҗе шәһәренең «Орешник» ял паркын билгеләргә.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Орешник» паркы территориясендә «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу» массакүләм чаңгы ярышларын үткәрү турында нигезләмә (1 нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу» массакүләм чаңгы ярышларын үткәрүгә чыгымнар сметасы (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының МБУ «Спорт мәктәбе»нә:

- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу-2021» массакүләм чаңгы ярышларын оештырырга һәм уздырырга;

- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу-2021» массакүләм чаңгы ярышлары үткәрү урынын әзерләүне оештырырга.

4. МКУ «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе»нә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәгариф учреждениеләрен әлеге күрсәтмә белән таныштырырга һәм аларның «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу-2021» массакүләм чаңгы ярышларында катнашуын тәэмин итәргә.

5. «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе»нә «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2021 чаңгы сезонын ябу» массакүләм чаңгы ярышлары чорында спорт чарасын медицина ярдәме белән тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. Әгерҗе районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенә “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2021 чаңгы сезонын ябу” массакүләм чаңгы ярышларын уздырганда иминлекне һәм озата баруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (Баженова О.А.) әлеге күрсәтмәне гамәлгә ашырганда финанслау мәсьәләсен хәл итәргә.

8. «Татмедиа» АҖ филиалы - «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясенә, «Әгерҗе радиосына» «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2021 чаңгы сезонын ябу-2021» массакүләм чаңгы ярышларын үткәрү барышы һәм нәтиҗәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

9. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

10. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлеге башлыгы Л.С. Имановага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
24 март 2021 № 61-р
күрсәтмәсенә 1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу» массакүләм чаңгы ярышларын үткәрү турында нигезләмә**

## 1. Максатлар һәм бурычлар

Ярышлар түбәндәге максатлар белән үткәрелә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чангы ярышларын популярлаштыру һәм үстерү;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
- физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә мотивацияли торган шартлар тудыру;
-иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау;
-Ярышларда катнашучыларның спорт осталыгын арттыру.

## 2. Уздыру урыны һәм сроклары.

Ярышлар **2021 елның 26 мартында** Әгерҗе шәһәренен «Орешник» ял паркында уздырыла. Җыелу һәм катнашучыларны теркәү 10.00 сәг. Ярышлар башлану вакыты 11.00 сәг.

## 3. Ярышларны уздыру һәм җитәкчелек итү.

Ярышларның гомуми җитәкчелеген Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ башкара. Ярышларны турыдан-туры уздыру судьялар коллегиясенә йөкләнә:

Баш судья – Яркеев Е.В.

Баш судья урынбасары– Орехов Г.М.

Трасса буенча баш судья урынбасары – Михайлов Э.И.

Өлкән судья – Семёнов А.Л.

Баш секретарь – Мөхүәммәтҗанова Н.В.

Баш секретарь урынбасары – Тукаева Г.Р.

Чаңгы ярышлары вакытында медицина ярдәмен тәэмин итү «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ учреждениесенә йөкләнә.

## 4. Ярышта катнашучылар.

Ярышларда чаңгы ярышлары буенча спорт әзерлеге булган, медицина тикшерүе узган һәм табибтан рөхсәт алган барлык теләүчеләр катнаша ала.

**Зурлар:** Ирекле стиль. Старт төре: масс – старт.

| Категория | Ир-атлар | Хатын-кызлар |
|---|---|---|
| 18-39 яшь | 5 км. | 3 км. |
| 40 яшь һәм өлкәнрәк | 5 км. | 3 км. |

**Мәктәп укучылары:** Ирекле стиль. Старт төре: эстафета, дистанция: 2 км.

**Командалар:**
I. 1-2 класс: 1 кыз, 1 малай,
3-4 класс: 1 кыз, 1 малай;
II. 5-7 класс: 1 кыз, 1 малай
III. 8-9 класс: 1 кыз, 1 малай;
IV. 10-11 класс: 2 малай, 2 кыз.

**5. Җиңүчеләрне ачыклау.**

Җиңүчеләр иң яхшы вакыт буенча билгеләнә. Үз яшь төркемнәрендә шәхси һәм команда зачетларында призлы урыннар алган катнашучылар грамоталар һәм медальләр белән бүләкләнә.

**6. Гаризалар**

Ярышларда катнашуга башлангыч гаризалар 2021 елның 25 мартыннан да соңга калмыйча spshcola@mail.ru электрон адресына юллана.

Контакт телефон: 885551 (2-34-20).

**7. Финанслау.**

Трассаны һәм бүләкләү материалларын әзерләүгә бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының массакүләм спорт өлкәсендә физик культура һәм спорт чараларына каралган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**Әлеге нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булып тора.**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
24 март 2021 № 61-р
күрсәтмәсенә 2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чаңгы сезонын ябу» массакүләм чаңгы ярышларын үткәрүгә чыгымнар сметасы**

**Бүләкләү материаллары:**

| | |
|---|---|
| Медальләр | 48 шт. х 100 сум = 4800 сум |
| Грамоталар | 21 шт. х 15 сум = 315 сум |
| ГСМ Буран (АИ 92) | 30 л. х 44 сум =1320 сум |
| **БАРЛЫГЫ:** | **6435,00 сум** |